РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
27.06.2022

КАРАР
№13

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлегенең 2021 елның 08 ноябренда
кабул ителгән 23нче номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлегендә инициативалы проектларны
тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибен
раслау турында карарына үзгәреш кертү

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 26 статьясы нигезендә, коррупциоген нормаларны бетерү максатларында,Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең 2021 елның 08 ноябренда кабул ителгән 23нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегендә инициативалы проектларнытәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибен раслау турында” карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 16 статьянытүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Статья 16. Инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу.

1. Конкурс нигезендә сайлап алуны комиссия башкара.

2. Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары, аларның әһәмияте, аларга тиешле баллар һәм үлчәү коэффициентлары 1 нче кушымтада (алга таба – критерийлар) билгеләнгән.

3. Конкурс нигезендә сайлап алу әлеге Тәртипнең 14 статьясы нигезендә үткәрелә торган комиссия утырышында башкарыла.

4. Комиссия инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны узган инициативалы проектларны ачыклау критерийлары нигезендә бәяләүне гамәлгә ашыра.

5. Конкурс нәтиҗәләре буенча йомгаклау бәясен исәпкә алып, комиссия инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны узган яисә узмаган дип игълан итү турында карар кабул итә.

6. Барлык критерийлар буенча максималь суммалы балл җыйган конкурс сайлап алуын узган инициатив проект игълан ителә.».

1.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау Тәртибенә1 нче кушымта нигезендә әлеге карарга кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан кененнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча һәм авыл җирлегенең информацион стендларында бастырырга

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А. Г. Гарипов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Шыңар
авыл җирлеге Советының 2022елның
27 июнендәге 13нче номерлы
карарына 1нче номерлы кушымта

**Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары**

| N т/б | Критерий исеме | Критерий буенча баллар |
|---|---|---|
| **1** | **Актуаль (кискен) проблемалар** | |
| Бик  югары - проблема халык тарафыннан критик дип бәяләнә, проблеманы хәл итү халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү һәм саклау өчен кирәк | | 10 |
| югары - проблема халык тарафыннан   шактый бәяләнә, аны хәл итмәү тормыш сыйфатына тискәре йогынты ясаячак | | 7 |
| уртача –хезмәт проблемасы халык тарафыннан актуаль дип бәяләнә, аны хәл итү тормыш сыйфатын яхшыртуга китерергә мөмкин | | 4 |
| **2** | **Проектны  тормышка ашыруга  комплекслы якын килү** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| **3** | **Халыкның аз керемле төркемнәре өчен инициативалы проектның җайлашуы** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| **4** | **Инициативалы проектны  хуплаучы гражданнар саны** | |
| 500дән артык кеше | | 10 |
| 250 дән 500 гә кадәр кеше | | 7 |
| 50дән 250 гә кадәр кеше | | 5 |
| 50гә кадәр кеше | | 3 |
| **5** | **Инициативалы проект нәтиҗәләрен  карап тоту (саклап калу) максатларында киләсе чорларда бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру зарурилыгы** | |

| | | |
|---|---|---|
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| **6** | **Оригинальлек, креативлык** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| **7** | **Инновацион технологияләр, яңа техник карарлар куллану** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| **8** | **Гаризада презентацион материаллар, дизайн-проект булу** | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| **9** | **Инициативалы проектны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда җәмәгатьчелекнең катнашуы** | |
| **9.1** | **Инициативалы проектның гомуми бәясеннән инициативалы түләүләр өлеше** | |
| Инициативалы проектның гомуми бәясенең 20% нан | | 10 |
| Инициативалы проектның гомуми бәясенең 15% тан 20 % ка кадәр | | 8 |
| Инициативалы проектның гомуми бәясенең 10% тан 15 % ка кадәр | | 5 |
| Инициативалы проектның гомуми бәясенең 0% тан 10% ка кадәр | | 1 |
| **9.2** | **Инициативалы проектны тормышка ашыруда мөлкәт һәм (яки) хезмәт катнашуы** | |
| | әйе | 5 |
| | юк | 0 |